**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«БОРДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«24» сентябрь, 2019 ел Борды авылы № 50/1

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге муниципаль берәмлеге уставы турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставын 1 кушымта нигезендә кабул итәргә.

2. Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Советының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

- «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Борды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы турында» 2012 елның 1 августындагы 20/1 санлы карары;
- «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Борды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2014 елның 15 декабрендәге 46/5 санлы карары;
- «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Борды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 29 июлендәге 12/1 санлы карары;
- «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Борды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 сентябрендәге 24/1 санлы карары;
- «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Борды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 25 июнендәге 34/1 санлы карары.

3. Әлеге карарны һәм «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставын законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә юнәлтергә.

4. Әлеге карарны һәм «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставын дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http:tukay.tatarstan.ru, pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карар дәүләт теркәвеннән соң рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе Р.Н.Абдульманова